**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы икътисады өчен аеруча мөһим әһәмияткә ия Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләре, акцияләре Татарстан Республикасы дәүләт милкендә булган акционер җәмгыятьләр исемлеген раслау турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» 2004 елның 26 июлендәге 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм «Татарстан Республикасының дәүләт мөлкәте турында» 2022 елның 23 декабрендәге 96-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы икътисады өчен аеруча мөһим әһәмияткә ия Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләре, акцияләре Татарстан Республикасы дәүләт милкендә булган акционер җәмгыятьләр исемлеген раслау турында» 2004 елның 8 октябрендәге ПУ-614 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2005 елның 20 июнендәге ПУ-264 номерлы, 2005 елның 10 августындагы ПУ-319 номерлы, 2005 елның 8 сентябрендәге ПУ-362 номерлы, 2007 елның 22 гыйнварындагы ПУ-17 номерлы, 2007 елның 23 августындагы ПУ-453 номерлы, 2007 елның 29 декабрендәге ПУ-717 номерлы, 2008 елның 17 гыйнварындагы ПУ-10 номерлы, 2008 елның 20 октябрендәге ПУ-529 номерлы, 2009 елның 24 октябрендәге ПУ-558 номерлы, 2010 елның 12 февралендәге ПУ-65 номерлы, 2012 елның 18 гыйнварындагы ПУ-22 номерлы, 2013 елның 14 мартындагы ПУ-228 номерлы, 2013 елның 27 августындагы ПУ-830 номерлы, 2015 елның 23 ноябрендәге ПУ-1126 номерлы һәм 2019 елның 6 маендагы ПУ-260 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы икътисады өчен аеруча мөһим әһәмияткә ия Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләре, акцияләре Татарстан Республикасы дәүләт милкендә булган акционер җәмгыятьләр исемлегенең 2 бүлегенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) преамбулада «Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында», «Хуҗалык җәмгыятьләре һәм ширкәтләренең идарә һәм контроль органнарында дәүләт вәкилләренең катнашу тәртибе турында» Татарстан Республикасы законнары нигезендә» сүзләрен

«Хуҗалык җәмгыятьләре һәм ширкәтләренең идарә һәм контроль органнарында дәүләт вәкилләренең катнашу тәртибе турында» 2000 елның 19 октябрендәге 383 номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» 2004 елның 26 июлендәге 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм «Татарстан Республикасының дәүләт мөлкәте турында» 2022 елның 23 декабрендәге 96-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 пунктта:

«а» пунктчасының беренче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга;

«а» пунктчасының икенче абзацында «ачык» сүзен төшереп калдырырга;

«б» пунктчасында «Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга;

в) Татарстан Республикасы икътисады өчен аеруча мөһим әһәмияткә ия Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләре, акцияләре Татарстан Республикасы дәүләт милкендә булган акционер җәмгыятьләр исемлегенең 2 бүлегендә:

5 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

16 һәм 17 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16. «Татавтодор» АҖ.

17. «Челтәр компаниясе» АҖ.»;

«*» билгесе куелган астөшермәдә «Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына әлеге Указны гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган карарлар кабул итәргә.

3. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2023 ел, 27 февраль
№ 120